**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«27 » сентябрь 2016 ел № 18

Муниципаль милектә булган җирләрдә
яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт
милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә
стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39, 33 статьялары, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен расларга.
2. Әлеге карар сәүдә объектларын бирү тәртибе законнары белән эш итә.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе В.И. Артемьев